# Кушма җөмләләр

Ике компонентлы кушма җөмлә катлаулы кушма җөмлә

тезмә кушма иярченле кушма

теркәгечле теркәгечсез аналитик синтетик

# **Бәйләүче чаралар:**

**Аналитик** ⟷ **синтетик**

**Мөнәсәбәтле сүзләр** **кушымчалар,**
**бәйлек**
**теркәгеч, теркәгеч сүзләр,** **һәм бәйлек**
**сүзләр**
**Күтәрү һәм аныклау интонациясе** **янәшәлек юлы**

- *1)Дус көйдереп әйтер, 2)дошман көлдереп әйтер.-* **ике компанентлы кушма җөмлә**.

- *1)Ут сүнде дә, 2)шәм кабыздым...*

  *3) караңгылык басты өйне. –* **катлаулы кушма җөмлә**

- *1)<u>Дус</u> көйдереп әйтер, 2)дошман көлдереп әйтер.*- **<u>ике компанентлы кушма җөмлә.</u>**

- *1)Ут сүнде дә, 2)шәм кабыздым...*

  *3) караңгылык басты өйне.* **<u>– катлаулы кушма җөмлә</u>**

- 1)**Авыр булды** миңа **аерылу,** 2**)  рәхәт булыр** кайткач **күрешү**!- **тезмә кушма җөмлә.**

- 1)Күк йөзе чалт аяз бул**са да**, 2)**кояш** инде алай **кыздырмый...- иярченле кушма җөмлә.**

- *Бүген таңда ап-ак* **карлар яуды**,2)*Ә кич белән* **бары да эреде**.- **теркәгечле тезмә кушма җөмлә.**

- *Юл ташларына* **яфрак коела***,* **Аккошлар** *инде юлга* **җыена**.- **теркәгечсез тезмә кушма җөмлә**

- *1)Берлек кайда,2) көч шунда.*- **аналитик иярченле кушма җөмлә.**

- *Йортлары янгач кешеләрнең күбесе 2) яңа йортлар торгызганнар*.- **синтетик иярченле кушма җөмлә**

- *Кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләр, сүзләр кебек үк, үзара* **тезү** *hәм* **ияртү** *юлы белән бәйләнәләр.*

- *Үзара тезү юлы белән бәйләнгән җөмләләрдән торган кушма җөмлә* **тезмә кушма җөмлә** *дип атала.*

- *Гади җөмләләре тезүче теркәгечләр ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә* **<u>теркәгечле тезмә кушма җөмлә</u>** *дип атала.*
- *Гади җөмләләре үзара интонация ярдәмендә бәйләнгән кушма җөмлә* ***<u>теркәгечсез кушма җөмлә</u>*** *дип атала*